РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

15.10.2019

№ 1217-п

2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районыныц авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны раслау турында

“Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында”гы 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2019 – 2025 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында”гы 2009 елнын 29 мартындагы 242 нче номерлы карарын үтәү йозеннән, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан бүлеп бирелә торган финанслау күләмнәре кысаларында 2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерүне тәэмин итү максатларында, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2019-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба мунициипаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча мунициипаль адреслы программаны (алга таба – Программа) расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Саба мунициипаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә (И. Б. Таипов):

2.1.2019-2025 елларда тозүчеләрдән бүлмәләр сатып алганда бирелә торган фатир мәйданнарын арттыруга чыгым күләмнәрен һәм аларны финанслау чыганакларын Министрлык белән килештерү юлы аша программа чараларының үтәлүен тәэмин итәргә;

2.2.бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба мунициипаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба мунициипаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы И.Б.Таиповка йокләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
1217 п, 15.10.2019
карары белән
РАСЛАНГАН

# 2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районыныц авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программа.

## Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаныц исеме | 2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программа (алга таба-Программа) |
| Муниципаль заказчы-программаның координаторы | Татарстан Республикасы Саба мунинипаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның топ чараларын башкаручылар | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы, Җир һәм молкәт монәсәбәтләре палатасы |
| Программаның топ максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты-билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерүне финанс һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.<br>Бурыч-Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының авария хәлендәге һәм яшәү очен яраксыз дип танылган торак фондыннан гражданнарны күчерү |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2019-2025 еллар, шул исәптән:<br>- 2019 ел этабы-2020 елның 31 декабренә кадәр;<br>- 2020 ел этабы-2021 елныц 31 декабренә кадәр;<br>- 2021 елныц этабы-2022 елныц 31 декабренә кадәр;<br>- 2022 елның этабы-2023 елның 31 декабренә кадәр;<br>- 2023 елныц этабы-2024 елныц 31 декабренә кадәр;<br>- 2024 ел этабы-2025 елның 1 сентябренә кадәр.<br>185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау :<br>-Дәүләт корпорациясе - торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд (алга таба-Фонд) - 34 149 435,32 сум;<br>- Татарстан Республикасы бюджеты – 6 509 494,68 сум-акчалары |

| | |
|---|---|
| | хисабына башкарыла.<br>Программаны финанслауның гомуми күләме-40 658 930 сум |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Төп чараларның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары программаның 1 кушымтасында китерелгән.<br>Программаны үтәүнең планлаштырылган күрсәткечләре, шул исәптән еллар буенча да, программаның 6 Кушымтасында китерелгән. |

## I. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итүнең кирәклеген нигезләү

Татарстан Республикасы һәм Саба муниципаль районында Дәүләт торак сәясәте торак өлкәсенең эшчәнлеге һәм үсеше проблемасын комплексы хәл итүгә юнәлдерелгән,ул шулай ук гражданнар очен торак алу мөмкинлеген тәэмин итә, анда яшәү очен куркынычсыз һәм уңайлы шартлар тудыра. Дәүлөт торак сәясәтенең төп бурычларыннан берсе булып - авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итү тора.

Программа “Яшәү өчен яраксыз булган торак фондын киметүне тәэмин итү” федераль проектын тормышка ашыру кысаларында һәм 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән.

Аварияле торак фонды ул - 2017 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән тәртиптә авария хәлендәге дип танылган күпфатирлы йортлардагы (алга таба – КФЙ) торак биналарның җыелмасы. Эксплуатацияләү процессында тузу сәбәпле алар җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиеш.

2017 елның 1 гыйнварына кадәр Саба муниципаль районында авария хәлендә дип 12 КФЙ дип танылды, аңа гомуми мәйданы 1410,8 кв. м булган 29 бина керә, аларда 81 кеше яши, шул исәптән:

- шәхси милектә-840,9 кв. м. га 15 бина;
– муниципаль милектә-569,9 кв. м. га 14 бина.

Авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның күбесе хәзерге вакытта билгеләнгән таләпләргә туры килә торган торак урыннарын мостәкыйль сатып ала алмый.

Авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү проблемасын хәл итүгә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетында күрсәтелгән гражданнарны күчерү очен җитәрлек акчалар булмау комачаулый.

Проблема, программаны тормышка ашыру кысаларында, авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү очен бүлеп бирелә торган Фонд һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанс ярдәме күрсәткәндә хәл ителергә мөмкин.

## II. Программаның топ максатлары, бурычлары һәм аны тормышка ашыру сроклары

Программаның төп максаты булып, билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге йортлардан гражданнарны күчерүне финанс һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тора. Бу очракта Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының 185-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән Фонд акчалары хисабына финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлешен тәэмин итүе төп шарт булып тора.

Куелган максатка ирешү өчен, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының авария хәлендә һәм яшәргә яраксыз дип танылган торак фондыннан гражданнарны күчерү бурычын хәл итү күздә тотыла.

2017 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән тәртиптә эксплуатацияләү процессында

тузу сәбәпле авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип танылган КФЙдан гражданнарны күчерүгә программаны гамәлгә ашыру кысаларында финанс ярдәме күрсәтү планлаштырыла. Бу КФЙ исемлеге программаның 2 Кушымтасында китерелгән.

Программа 2019 елдан 2025 елның 1 сентябренә кадәр гамәлгә ашырылачак.

Программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары программаның 1 кушымтасында китерелгән.

Этаплар буенча программаны үтәүнең планлаштырылган күрсәткечләре программаның 6 Кушымтасында китерелгән.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча чараларны гамәлгә ашыру очен финанс чаралары Фонд һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына формалаштырыла. Программаны гамәлгә ашыруга гомуми чыгымнар барлык финанслау чыганаклары хисабына 40 658 930 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән :

- Фонд-34 149 435,32 сум (83,99 сум%);
- Татарстан Республикасы бюджеты - 6 509 494,68 сум (16,01%)-акчалары.

Программаны финанслау чаралары күләме, Программага кертелгән, эксплуатация процессында физик тузу сәбәпле, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип танылган КФЙ исемлеге нигезендә, гражданнарга бирелә торган торак урыннарының гомуми мәйданының планлаштырыла торган бәясе күләме, Программага кертелгән авария хәлендәге КФЙда гражданнар (юридик затлар) милкендәге алына торган торак биналарның гомуми мәйданының бер квадрат метрына сатып алу бәясенен планлаштырыла торган күләме, шулай ук Программаның 3 нче кушымтасы нигезендә бирелгән гражданнарны күчерү ысуллары белән билгеләнә.

2019-2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен финанс ярдәме чараларын бүлү Программаның 4 нче кушымтасында китерелгән.

Бер квадрат метрның түләп алу бәясе Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 7 олеше нигезендә билгеләнә.

Программа нигезендә гражданнарга бирелә торган торак урыннарының гомуми мәйданының планлаштырыла торган бәясе күләме:

- 2019 ел этабында-41 000 сум;
- 2020 ел этабында-42 000 сум;
- 2021 ел этабында-43 000 сум;
- 2022 ел этабында-44 000 сум;
- 2023 ел этабында-45 000 сум;
- 2024 ел этабында-46 000 сум.

Күрсәтелгән бәяләр якынча бирелгән һәм муниципаль ихтыяҗлар очен биналар сатып алуга электрон аукцион нәтиҗәләре буенча үзгәрергә момкин.

Россия Федерациясе Торак кодексының 86 һәм 89 статьялары нигезендә авария хәлендәге торак фондыннан күчерелүче гражданнарга, авария хәлендәге КФЙ урнашкан торак пункттагы кебек үк уңайлыклары булган, торак законнары белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм авария хәлендәге КФЙ урнашкан торак пункты чикләрендә яисә Татарстан Республикасының башка торак пункты чикләрендә урнашкан, алдагы яшәгән торак урыннарының гомуми мәйданына тигез булган, гражданнарның язма ризалыгы белән Россия Федерациясе Торак кодексының 89 статьясындагы 1 өлеше нигезендә торак урыны бирелә.

Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясы нигезендә авария хәлендәге торак фондының торак урыннары милекчеләренә, шулай ук закөнлы коченә кергән суд актлары нигезендә, тузган торакта урнашкан сатып алынган торак урыны өчен түләү исәбенә, алынган торак урыны урынына төзекләндерелгән торак урыннары бирелә.

Сатып алына торган торак урыннарына карата таләпләр программаның 5 Кушымтасында китерелгән.

Фонд, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән алынган җирле бюджет

акчалары :

- КФЙда яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында (алга таба - блокланган төзелеш йортлары) күрсәтелгән йортларда төзүчеләрдән торак биналар сатып алуга һәм шушы йортларның төзелешенә;

- 185-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә авария хәлендәге торак фондына керә торган торак урыннары булган затларга Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясы нигезендә алынган торак урыны өчен түләүгә;

- 185-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә, бу биналар урнашкан йорт төзүчеләр булмаган затлардан аларны авария хәлендәге торак фондыннан күчерелүче гражданнарга бирү өчен торак биналар сатып алуга тотыла.

Программаны өлешләп финанслау күләме:

- 2024 ел этабы-100,0%.

## IV. Программа чараларын тормышка ашыру механизмы, программа белән идарә итүне оештыру һәм аны тормышка ашыруны контрольдә тоту

Муниципаль заказчы-координатор программаны гамәлгә ашыру барышына гомуми җитәкчелек итә һәм контрольдә тота, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба-министрлык), программаны үтәүчеләр белән планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне оештыра.

- Программаны башкаручылар:
- программаны эшләү һәм раслауны;
- 185-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында каралган Фонд акчалары исәбеннән финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне;
- муниципаль берәмлек территориясендә авария хәлендәге торак фондына инвентаризация үткәрү һәм аннан соң мониторинг үткәрүне;
- гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә юнәлдерелгән акчаларны тоту турында хисап алып бару һәм аны дәүләт заказчысына тапшыруны;
- гражданнарны авария хәлендәге һәм яшәү өчен яраксыз дип танылган торак фондтан күчерүгә бәйле рәвештә, социаль найм килешүләре һәм торак биналарның милекчеләре белән килешүләр буенча торак биналар бирүне;
- КФЙ төзелгән очракта, гражданнарны аварияле торак фондыннан күчерү өчен билгеләнгән йортлар төзелешенә проект документациясен эшләүне;

КФЙ (блоклы төзелеш йортлары) төзелешенә, торак биналар, торак биналарны сатып алуга муниципаль контрактлар төзү һәм сатып алуны;

- гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә юнәлдерелгән бюджет чараларын куллануны контрольдә тотуны;
- азат ителгән торак урыннарны муниципаль милеккә күчерүне тәэмин итәләр.

Программаны үтәүчеләр Программа чараларын тормышка ашыру, аларның ахыргы нәтиҗәләре, бүлеп бирелә торган финанс чараларын максатчан куллану өчен җаваплы һәм чараларны тормышка ашыру турында муниципаль заказчы - программаның координаторына мәгълүмат тапшыралар.

Муниципаль заказчы – программаның координаторы билгеләнгән вакытта министрлыкка, шулай ук Саба муниципаль районының финанс-бюджет палатасына программаны тормышка ашыру барышы һәм финанс чараларын тоту турында хисап тапшыра.

## V. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып, 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган, Фонд һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанс ярдәме белән, авария хәлендәге торак йортлардан гражданнарны уңышлы (тулы) күчерү тора.

Этаплар бүленешендә бирелгән нәтиҗәлелекнең планлаштырылган күрсәткечләре программаның 6 Кушымтасында китерелгән.

Программаны тормышка ашыру:

- гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларына хокукларын тормышка ашыруны;
- билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип танылган КФЙда яшәүче халыкның олешен киметүие;
- җәмгыятьтә соңиаль киеренкелекне киметүне;
- авария хәлендәге торак фондын бетерү хисабына Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең тышкы күренешен яхшыртуны тәэмин итәчәк.

2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районыныц авария
хәлендәге торак фондыннан гражданнарны
күчерү буенча муниципаль адреслы программага
1 нче кушымта

**2019-2025 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АВАРИЯ ХӘЛЕНДӘГЕ ТОРАК ФОНДЫННАН ГРАЖДАННАРНЫ КҮЧЕРҮ БУЕНЧА МУНИЦИПАЛЬ АДРЕСЛЫ ПРОГРАММАНЫҢ ТОП ЧАРАЛАРЫНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ**

| Программаны үтәү күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Программаны үтәү нәтиҗәсендә ирешелгән күрсәткечләр |
|---|---|---|
| 2019 - 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын үтәү нәтиҗәсендә күченгән халык саны (алга таба-Программа) | Кеше | 81 |
| Авария хәлендәге күпфатирлы йортларда теркәлгән, аңа кертелгән йортларда яшәүчеләрнең гомуми саныннан чыгып, программаны үтәү кысаларында күчерелгән халыкның өлеше | Процент | 100 |
| Программаны үтәү кысаларында яшәүчеләре күчерелгән аварияле дип танылган күпфатирлы йортлар саны | Данә | 12 |
| Программаны үтәү кысаларында яшәүчеләре күчерелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортларның өлеше | Процент | 100 |
| Программаны тормышка ашыру кысаларында торак һәм торак булмаган биналар буенча бушатылган биналарның гомуми саны (яллау, сатып алу һәм квадрат метрлар суммасында) | Данә | Гомуми мәйданы 1 410,8 кв. м булган 29 бина |
| 2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә дип танылган һәм файдалану барышында тузу сәбәпле сүтелергә тиешле барлык күпфатирлы йортларга карата Программаны үтәү кысаларында яшәүчеләре күчерелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортларның өлеше | Процент | 100 |
| Программаны үтәү өчен Татарстан Республикасына карата торак - коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды-дәүләт корпорациясе чаралары лимитыннан тотылган акчалар өлеше | Процент | 100 |

2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының авария
хәлендәге торак фондыннан гражданнарны
күчерү буенча муниципаль адреслы программага
2 нче кушымта

**2017 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән тәртиптә файдалану барышында тузу сәбәпле авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип танылган КФЙ исемлеге; Бу КФЙдан гражданнарны күчерү очен программаны гамәлгә ашыру кысаларында финанс ярдәме күрсәтү планлаштырыла**

| N п/п | Күпфатирлы йортның адресы | Йортны файдалануга тапшыру елы | Күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану датасы | 2025 елның 1 сентябренә кадәр яшәүчеләре урнаштырылып бетерелергә тиешле авария хәлендәге торак фонды турында белешмәләр | | Күчерүне тәмамлауның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ел | дата | мәйдан, кв. м | Кеше саны | дата |
| 1 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 2019-2025 елларны күчерү программасы буенча, аның кысаларында каралган | | х | х | 1 410,80 | 81 | х |
| 1 | Байлар Сабасы ш.т.п., Гагарин ур., 16 йорт | 1980 | 30.07.2012 | 194,40 | 6 | 31.08.2025 |
| 2 | Байлар Сабасы ш.т.п., Завод ур., 14 йорт | 1982 | 27.07.2012 | 174,60 | 6 | 31.08.2025 |
| 3 | Байлар Сабасы ш.т.п., Тукай ур., 90 йорт | 1970 | 04.05.2012 | 180,50 | 12 | 31.08.2025 |
| 4 | Байлар Сабасы ш.т.п., Тукай ур., 108 йорт | 1962 | 19.05.2012 | 114,00 | 14 | 31.08.2025 |
| 5 | Иштуган тимер юл аерылышы авылы, Беренче Май ур., 12 йорт | 1982 | 20.11.2012 | 51,40 | 5 | 31.08.2025 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Иштуган тимер юл аерылышы авылы, Беренче Май ур., 24 йорт | 1988 | 21.09.2012 | 92,30 | 5 | 31.08.2025 |
| 7 | Мондеш тимер юл аерылышы авылы, Газовиклар ур., 1 йорт | 1970 | 08.08.2012 | 80,50 | 2 | 31.08.2025 |
| 8 | Мондеш тимер юл аерылышы авылы, Газовиклар ур., 5 йорт | 1970 | 03.09.2012 | 35,50 | 3 | 31.08.2025 |
| 9 | Шәмәрдән авылы, Азии ур., 14 йорт | 1997 | 25.09.2012 | 137,30 | 5 | 31.08.2025 |
| 10 | Шәмәрдән авылы, Коммунальная ур., 18а йорты | 1983 | 19.10.2012 | 87,70 | 4 | 31.08.2025 |
| 11 | Шәмәрдән авылы, Лермонтов п., 3а йорты | 1991 | 21.09.2012 | 102,60 | 8 | 31.08.2025 |
| 12 | Шәмәрдән авылы, Яңа Юл ур., 6 йорт | 1986 | 30.07.2012 | 160,00 | 11 | 31.08.2025 |

2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районынын авария
хәлендәге торак фондыннан гражданнарны
күчерү буенча муниципаль адреслы программага
3 нче кушымта

# 2017 ЕЛНЫҢ 1 ГЫЙНВАРЫНА АВАРИЯ ХӘЛЕНДӘ ДИП ТАНЫЛГАН ТОРАК ФОНДЫННАН ГРАЖДАННАРНЫ КҮЧЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ПЛАНЫ

| № п/п | Наименование муниципального образования | Всего расселяемая площадь жилых помещений, кв.метров | Расселение в рамках Программы, не связанное с приобретением жилых помещений и связанное с приобретением жилых помещений без использования бюджетных средств | | | | | Расселение в рамках Программы, связанное с приобретением жилых помещений за счет бюджетных средств | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | всего | в том числе | | | | всего | | | в том числе | | | | | | | |
| | | | | выкуп жилых помещений у собственников | | договор о развитии застроенной территории | переселение в свободный жилищный фонд | | | | строительство домов | | приобретение жилых помещений у застройщиков, в том числе: | | | | приобретение жилых помещений у лиц, не являющихся застройщиками | |
| | | | | | | | | | | | | | в строящихся домах | | в домах, введенных в эксплуатацию | | | |
| | | | расселяемая площадь, кв.метров | расселяемая площадь, кв.метров | стоимость, рублей | расселяемая площадь, кв.метров | стоимость, рублей | расселяемая площадь, кв.метров | приобретаемая площадь, кв.метров | стоимость, рублей | приобретаемая площадь, кв.метров | стоимость, рублей | приобретаемая площадь, кв.метров | стоимость, рублей | приобретаемая площадь, кв.метров | стоимость, рублей | приобретаемая площадь, кв.метров | стоимость, рублей |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| | Всего по адресной программе по переселению граждан из аварийного жилищного фонда на 2019 – 2025 годы, в рамках которой предусмотрено финанси-рование за счет средств Государственной корпорации – Фонда содействия реформиро-ванию жилищно-коммунального хозяйства, | 1 410,80 | 840,90 | 840,90 | 9 200 450,00 | 0,00 | 0,00 | 569,90 | 683,88 | 31 458 480,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 683,88 | 31 458 480,00 | 0,00 | 0,00 |
| | Всего по этапу 2024 года | 1 410,80 | 840,90 | 840,90 | 9 200 450,00 | 0,00 | 0,00 | 569,90 | 683,88 | 31 458 480,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 683,88 | 31 458 480.00 | 0.00 | 0.00 |
| 1. | Итого по Сабинскому муниципальному району | 1 410,80 | 840,90 | 840,90 | 9 200 450,00 | 0,00 | 0,00 | 569,90 | 683,88 | 31 458 480,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 683,88 | 31 458 480,00 | 0,00 | 0,00 |

2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районыныц авария
хәлендәге торак фондыннан гражданнарны
күчерү буенча муниципаль адреслы программага
4 нче кушымта

# 2017 ЕЛНЫҢ 1 ГЫЙНВАРЫНА АВАРИЯ ХӘЛЕНДӘ ДИП ТАНЫЛГАН ТОРАК ФОНДЫННАН ГРАЖДАННАРНЫ КҮЧЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАРНЫҢ ПЛАНЫ

| № п/п | Наименование муниципального образования | Число жителей, планируемых к переселению, человек | Количество расселяемых жилых помещений | | | Расселяемая площадь жилых помещений | | | Источники финансирования Программы | | | | Справочно: расчетная сумма экономии бюджетных средств | | | Справочно: возмещение части стоимости жилых помещений | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | всего, еди-ниц | в том числе | | всего, кв.метров | в том числе | | всего, рублей | в том числе | | | всего, рублей | в том числе | | всего, рублей | в том числе | |
| | | | | собствен-ность граждан, еди-ниц | муници-пальная собствен-ность, еди-ниц | | собствен-ность граждан, кв.метров | муниципаль-ная собствен-ность, кв.метров | | за счет средств Фонда, рублей | за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации, рублей | за счет средств местного бюджета, рублей | | за счет переселения граждан по договору о развитии застроенной территории, рублей | за счет переселения граждан в свободный муниципальный жилищный фонд, рублей | | за счет средств собственников жилых помещений, рублей | за счет средств иных лиц (инвестора по ДРЗТ), рублей |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| | Всего по адресной программе по переселению граждан из аварийного жилищного фонда на 2019 – 2025 годы, в рамках которой предусмотрено финанси-рование за счет средств Государственной корпорации – Фонда содействия реформиро-ванию жилищно-коммунального хозяйства, в том числе: | 81 | 29 | 15 | 14 | 1 410,80 | 840,90 | 569,90 | 40 658 930,00 | 34 149 435,32 | 6 509 494,68 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| | Всего по этапу 2024 года | 81 | 29 | 15 | 14 | 1 410,80 | 840,90 | 569,90 | 40 658 930,00 | 34 149 435,32 | 6 509 494,68 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0 00 | 0 00 |
| 1. | Сабинский муниципальный район | 81 | 29 | 15 | 14 | 1 410,80 | 840,90 | 569,90 | 40 658 930,00 | 34 149 435,32 | 6 509 494,68 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |

2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының авария
хәлендәге торак фондыннан гражданнарны
күчерү буенча муниципаль адреслы программага
5 нче кушымта

# 2019-2025 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫЦ АВАРИЯ ХӘЛЕНДӘГЕ ТОРАК ФОНДЫННАН ГРАЖДАННАРНЫ КҮЧЕРҮ БУЕНЧА МУНИЦИПАЛЬ АДРЕСЛЫ ПРОГРАММА КЫСАЛАРЫНДА ТӨЗЕЛӘ ЯИСӘ САТЫП АЛЫНА ТОРГАН ТОРАККА ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ТАЛӘПЛӘР

Әлеге таләпләрне, муниципаль заказчыларга, гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү адреслы программаларын гамәлгә ашыру максатларында сатып алулар үткәрүгә документлар әзерләгәндә исәпкә алырга киңәш ителә. (Милекчеләрдән биналарны сатып алуга контрактлардан һәм файдалануга тапшырылган йортларда тозүчеләр булмаган затлардан торак сатып алуга контрактлардан тыш). Файдалануга тапшырылган йортларда, тозүчеләр булмаган затлардан торак урыннары сатып алуга контрактлар буенча сатып алына торган торак урыннарына карата таләпләр, дәүләт (муниципаль) заказчысы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

| N п/п | Таләпнең исеме | Таләпнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1 | Өйгә карата проект документларына таләпләр | Проект документларында торак параметрларының проект әһәмияте һәм башка проект характеристикалары, шулай ук аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча проектлана торган чаралар, аны тозегәндә һәм файдалануга тапшырганда гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге очен (инвалидларны һәм мөмкинлекләре чикләнгән халыкның башка төркемнәрен дә кертеп), физик һәм юридик затларның милке, дәүләт яки муниципаль милек, әйләнә-тирә мохит очен куркынычсыз булырга тиеш.<br>Проект документлары түбәндәге таләпләр нигезендә эшләнә:<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Проект документлары бүлекләре составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында” 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карарлары;<br>- “Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент” 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- “Биналарның һәм корылмаларның иминлеге турында Техник регламент” 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- СП 42.13330.2016 “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү”;<br>- СП 54.13330.2016 “Күпфатирлы торак биналар”;<br>- СП 59.13330.2016 “Аз хәрәкәтләнүче халык төркемнәре өчен биналарга һәм корылмаларга керү мөмкинлеге булу”; |

| | | |
|---|---|---|
| | | - СП 14.13330.2014 “Сейсмик районнарда тозелеш”;<br>- СП 22.13330.2016 “Биналар һәм корылмаларга нигез салу”;<br>- СП 2.13130.2012 “Янгыннан саклау системалары. Саклау объектларының янгынга каршы торучанлыгын тәэмин итү”;<br>- СП 4.13130.2013 “Янгыннан саклау системалары. Саклау объектларында янгын таралуны чикләү. Күләмле-планлаштырылган һәм конструктив чишелешләргә карата таләпләр”;<br>- СП 255.1325800 “Биналар һәм корылмалар. Куллану кагыйдәләре. Гомуми нигезләмәләр”.<br>Проект документациясен рәсмиләштерү “Проект һәм эш документларына төп таләпләр” 21.11.2011-2013 ГОСТ нигезендә гамәлгә ашырыла.<br>Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән төзелешләре планлаштырыла торган күпфатирлы йортлар, шулай ук сатып алынырга тиешле торак йортлар Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2010 елның 10 июнендәге 64 карары (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) белән расланган “Торак йортларда һәм биналарда яшәү шартларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр” СанПиН 2.1.2645-10 нигезләмәләренә туры килергә тиеш. |
| 2 | Әзер торак сатып алына торган файдалануга тапшырылучы күпфатирлы йортны һәм төзелүче күпфатирлы йортны конструктив, инженерлык һәм технологик яктан тәэмин итүгә таләп | Төзелеп килүче йортлар(ның) :<br>- йорт төзелешенә проект документларына карата шәһәр төзелеше законнары таләпләре нигезендә үткәрелгән экспертизаның уңай бәяләмәсе булырга тиеш;<br>- төп төзелеш конструкцияләре түбәндәге материаллардан булырга тиеш:<br>а) таш конструкцияләрдән (кирпеч, блоклар), эре тимер-бетон блоклардан, тимер-бетон панельләрдән, монолит тимер-бетон каркастан диварлар.;<br>б) җыелма һәм монолит тимер-бетон конструкцияләреннән түшәмәләр;<br>в) җыелма һәм монолит тимер-бетон һәм таш конструкцияләрдән фундаментлар.<br>Җиңел корыч юка диварлы конструкцияләрдән (ЛСТК), SIP панельләр, металл сэндвич-панельләрдән йортлар төзү һәм андый йортлардан торак сатып алу киңәш ителми;<br>- тиешле ресурслар белән тәэмин итүче һәм башка оешмалар тарафыннан бирелгән техник шартлар буенча үзәкләштерелгән инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташкан булырга тиеш;<br>- үз эченә ваннаны, унитазны, раковинаны алган фатир эчендәге санитар үзәге (аерым яки берләштерелгән) булырга тиеш;<br>- йорт эчендәге инженерлык системалары, шул исәптән:<br>а) электр белән тәэмин итү (көч һәм башка электр җиһазлары белән проект документлары нигезендә); |

| | | |
|---|---|---|
| | | б) салкын су белән тәэмин итү;<br>в) су китү (канализация);<br>г газ белән тәэмин итү (проект документлары нигезендә булган очракта), авария-диспетчерлык хезмәте күрсәтү мөмкинлеге булган торак бинаның эчке газ үткәргечендә газ барышы буенча беренче булып билгеләнгән тиз гамәлдә булган чит ил клапаны белән блокланган газ белән тәэмин итү сигнализаторларын урнаштыру (проект документлары нигезендә);<br>д) җылыту (үзәкләштерелгән җылыту системасы булмаганда һәм газ булганда коллектив яки индивидуаль газ казаннары урнаштыру киңәш ителә);<br>е) кайнар су белән тәэмин итү;<br>ж) янгын куркынычсызлыгы (проект документлары нигезендә);<br>з) чүп-чар ташлау (проект документлары нигезендә булган очракта) системалары булырга тиеш;<br>- икътисадый максатчанлык очрагында электр белән тәэмин итүнең локаль системалары;<br>- файдалануга кабул ителгән һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән лифтлар (проект документлары нигезендә булган очракта) булырга тиеш.<br>Лифтларны :<br>а) озата баручы зат белән кресло-коляскада инвалид файдалану очен билгеләнгән кабина;<br>б) диспетчер белән элемтә очен җиһазлар;<br>в) лифт кабинасын авария яктырту;<br>г) вандалларга каршы башкарылган лифт кабинасын светодиод яктырту;<br>д) вандалга каршы башкаруда лифт кабинасы белән идарә итү панеле белән җиһазландыру киңәш ителә.;<br>- тиешле ресурс белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан файдаланугакабул ителгән һәм электр энергиясен, салкын суны, кайнар суны исәпкә алу буенча гомумйорт (күмәк) приборлары классларына билгеләнгән таләпләргә туры килгән үлчәүләрнең (билгеләнгән очракларда үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин иткәндә) дәүләт реестрына кертелгән чаралары;<br>- җиңел алып атыла торган тәрәзә блоклары;<br>- светодиод яктылык чыганагы булган вандалларга каршы башкару яктырткычларын, хәрәкәт датчикларын һәм яктырткычларны кулланып йорттагы баскыч мәйданчыкларын яктырту;<br>- йорт подъездларына кергәндә яктылык диодлары белән яктырткычлар һәм яктылык датчиклары булган вандалларга каршы башкаруда яктырту, керү ишегендәге козыреклар, тоткалар һәм үзләре ябыла торган, җылытылган ишек блоклары;<br>- йортның подвалга (техник идәндә) керү урыннарында |

| | | |
|---|---|---|
| | | йозаклы, тоткычлы һәм үзе ябыла торган металл ишек блоклары;<br>- йортның бөтен периметры буенча корылган һәм фундаменттан су бирүне тәэмин итә торган армацияләнгән бетоннан, асфальттан отмостка;<br>- су агып тошә торган торбалар;<br>- йорт яны территориясен төзекләндерү, шул исәптән каты катлам, яшелләндерү һәм кече архитектура формалары, төрле билгеләнештәге гомуми кулланылыштагы мәйданчыклар, шул исәптән уен комплексы булган балалар уен мәйданчыгы (проект документлары нигезендә) булырга тиеш. |
| 3 | Функциональ җиһазлауга һәм биналарны бизәүгә таләпләр | Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү очен төзелгән һәм сатып алынган торак биналар йортның подвал, цоколь, техник, мансардлыдан кала теләсә кайсы катларында урнашырга тиеш һәм алар:<br>- йорт эчендәге тиешле инженерлык системаларына тоташтырылган фатир эчендәге инженерлык челтәрләре белән җиһазландырылган булырга тиеш,шулай ук:<br>а) электр щиты һәм саклагыч сүндерү җайланмасы булган электр белән тәэмин итү;<br>б) салкын су белән тәэмин итү;<br>в) кайнар су белән тәэмин итү (үзәкләштерелгән яки автоном);<br>г) су китү (канализация);<br>д) җылыту (үзәкләштерелгән яки автономияле);<br>е) вентиляция;<br>ж) газ белән тәэмин итү (проект документлары нигезендә булган очракта);<br>з) тиешле ресурс белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан файдалануга кабул ителгән һәм электр энергиясен, салкын суны, кайнар суны, табигый газны исәпкә алу буенча индивидуаль приборларның төгәллеге классларына тиешле таләпләргә туры килә торган (билгеләнгән очракларда) предприятие-җитештерүчеләр үлчәү чаралары белән дәүләт реестрына кертелгән үлчәү чаралары (проект документлары нигезендә) булырга тиеш;<br>- эчке бүлмәләре тулысынча эшләнгән булырга тиеш ,шул исәптән:<br>а) йозаклы, тоткычлы һәм карау өлеше булган җылытылган керү ишеге;<br>б) йөзлек һәм тоткычлар белән бүлмә ишекләре;<br>в) тәрәзә төпләре һәм энергия ягыннан нәтиҗәлелек классына (ике позициядә кәүсәләрен (фрамуг, форточка) ачу мөмкинлеге булган) керә торган пыяла пакет белән җицел алып ташлана торган тәрәзә блоклары ;<br>г) вентиляцион рәшәткә;<br>д) фатирның барлык бүлмәләрендә түшәмдә яктырту җайланмалары өчен асылынып тора торган элгечләр; |

| | | |
|---|---|---|
| | | е) тиешле фатир эчендәге инженерлык челтәрләренә урнаштырылган һәм тоташтырылган.:<br>- шалтырату сигнализациясе (проект документлары нигезендә);<br>- су краны һәм сифон белән юынгыч;<br>- су краны һәм сифон белән кулъюгыч;<br>- су багы һәм утыргыч белән унитаз;<br>- җиргә беркетелгән су краны һәм сифон белән ванна;<br>- бер-ике клавишлы электр сүндергечләр;<br>- электр розеткалары;<br>- фатирның барлык биналарында электр үткәргечләр һәм патроннар чыгару;<br>- газ яки электр плитәсе (проект карары нигезендә);<br>- җылылык көйләгече булган җылылык радиаторлары (проект документлары нигезендә технологик мөмкинлек булганда), ә автоном җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итү булганда ике контурлы казан булырга тиеш;<br>Ж) ванна бүлмәсе, бәдрәф (санузел), кладовый бүлмәләрендә, балконда керамик плитәдән (лоджия), фатирның калган бүлмәләрендә - тузу чыдамлыгы 22 класслы һәм аннан югарырак булган ламинат яки көбек тутырылып ясалган нигезле линолеумнан идән япмалары.;<br>з) ванна, туалет, кухня, кладовой бүлмәләрендәге диварларны су эмульсиясе белән ясалган яки шуңа ошаган икенче төрле буяу белән эшләргә,(кухняның эшләү өстәленә һәм ваннаны кулъюгычка якын керамик плитә белән тышлана торган урыннарыннан тыш);башка бүлмәләрнең диварларына обой ябыштырылырга тиеш;<br><br>е) фатирның барлык бүлмәләрендә дә түшәм су эмульсиясе белән ясалган яки шуңа ошаган икенче төрле буяу яки металл яки пластик профильгә беркетелгән винил пленкасыннан (ПВХ) яки җөйсез тукымадан ясалган конструкция белән эшләнергә тиеш. |
| 4 | Материалларга, эшләнмәләргә һәм җиһазларга таләпләр | Күпфатирлы йортны төзү проектын эшләүчеләргә заманча сертификацияләнгән төзелеш һәм бизәү материаллары, эшләнмәләр, технологик һәм инженер җиһазларын куллануны күздә тотарга тәкъдим ителә.<br>Төзелеш торакның проект документлары таләпләренә туры килүен тәэмин итүче материаллар һәм җиһазлар кулланып башкарылырга тиеш.<br>Йорт төзелеше барышында башкарыла торган эшләр һәм кулланыла торган төзелеш материаллары, гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү максатларында, муниципаль контракт нигезендә сатып алына торган торак йортлар, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләре капиталь төзелеш объектының техник регламентларның таләпләренә, |

| | | |
|---|---|---|
| | | энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә туры килергә тиеш. |
| 5 | Йортның энергия ягыннан нәтиҗәлелегенә таләп | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 6 июнендәге 399/боерыгы белән расланган энергетика нәтиҗәлелеге классын билгеләү кагыйдәләре буенча йортның энергия ягыннан нәтиҗәлелеге "B" классыннан ким булмаска тиеш.<br>Йортның энергия ягыннан нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән түбәндәге чараларны күздә тотарга киңәш ителә:<br>- фатирлардагы һәм гомуми файдаланудагы биналарда тәрәзә блокларына югарыда күрсәтелгән өстәмә таләпләр кую;<br>- гомуми кулланылыштагы биналарда, баскыч читлекләрендә, подъездларга керү алдыннан хәрәкәт һәм яктылык датчиклары булган светодиод яктырткычларны урнаштыру;<br>- йорт яны территориясен яктыртуны светодиод яктырткычлар һәм яктылык датчиклары ярдәмендә башкарырга;<br>- подвал (цоколь) һәм чорма түшәмәләренең җылылык изоляциясен (проект документлары нигезендә) башкарырга;<br>- проект документларында каралган кайнар һәм салкын су белән тәэмин итүне, электр энергиясен, газны һәм башкаларны исәпләү приборларын урнаштыруны үткәрергә;<br>- җылылык радиаторларын җылылык көйләгече булган җайланмалар белән урнаштырырга (проект документлары нигезендә технологик мөмкинлек булганда);<br>- подъездларга үзләре ябыла торган һәм җылытылган керү ишекләрен урнаштыру;<br>- йорт подъездларына җылытылган диварлар белән керү тамбурлары урнаштырырга, җылытылган һәм үзләре ябыла торган тамбур (керү һәм керү юллары) ишекләрен урнаштырырга.<br>Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 6 июнендәге 399/пр номерлы боерыгы белән расланган Күпфатирлы йортларның энергетика нәтиҗәлелеге классларын билгеләү кагыйдәләренең III бүлеге нигезендә йорт фасадында йортның энергетика нәтиҗәлелеге классының күрсәткече булуны тәэмин итәргә. |
| 6 | Йортның файдалануга тапшыру документларына таләпләр | Җитештерүче предприятиеләрнең Механик, электр, санитар-техник һәм башка төр, шул исәптән лифт җайланмаларын, энергетика ресурсларын куллануны исәпкә алу приборларын (гомумйорт (күмәк) һәм индивидуаль) һәм энергетика ресурсларын бирү белән идарә итү үзәкләрен һ. б. куллану буенча паспортлары һәм инструкцияләре булырга, |

| | | |
|---|---|---|
| | | шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы Карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 24 һәм 26 пунктларында каралган, шул исәптән, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 10.1 пункты (биналарны куркынычсыз эксплуатацияләүгә таләпләр) һәм "255.1325800" СП. "Биналар һәм корылмалар. Куллану кагыйдәләре. Гомуми нигезләмәләр" (проект документациясе нигезендә) нигезендә башкарылган күпфатирлы йортны файдалану күрсәтмәсен дә кертеп башка тиешле документлары булырга тиеш.<br>Фатир эчендәге инженерлык жиһазларын куллану буенча күрсәтмәләр булырга тиеш. Фатир эчендәге инженерлык җиһазларын куллану буенча күрсәтмә комплектлары заказ бирүчегә тапшырылырга тиеш. |

2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районыныц авария
хәлендәге торак фондыннан гражданнарны
күчерү буенча муниципаль адреслы программага
6 нчы кушымта

# 2017 ЕЛНЫҢ 1 ГЫЙНВАРЫНА АВАРИЯ ХӘЛЕНДӘ ДИП ТАНЫЛГАН ТОРАК ФОНДЫННАН ГРАЖДАННАРНЫ КҮЧЕРҮНЕҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ

| № п/п | Наименование муниципального образования | Расселяемая площадь, кв.метров | | | | | | | | Количество переселяемых жителей, человек | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 г. | 2020 г. | 2021 г. | 2022 г. | 2023 г. | 2024 г. | 2025 г. | всего | 2019 г. | 2020 г. | 2021 г. | 2022 г. | 2023 г. | 2024 г. | 2025 г. | всего |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 |
| | Всего по адресной программе по переселению граждан из аварийного жилищного фонда на 2019 – 2025 годы, в рамках которой предусмотрено финанси-рование за счет средств Государственной корпорации – Фонда содействия реформиро-ванию жилищно-коммунального хозяйства, в том числе: | х | х | х | х | х | 211,62 | 1 199,18 | 1 410,80 | х | х | х | х | х | 12 | 69 | 81 |
| | Всего по этапу 2024 года | х | х | х | х | х | 211,62 | 1 199,18 | 1 410,80 | х | х | х | х | х | 12 | 69 | 81 |
| 1. | Сабинский муниципальный район | х | х | х | х | х | 211,62 | 1 199,18 | 1 410,80 | х | х | х | х | х | 12 | 69 | 81 |